ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

29.01.2025 г. Казань № 10-од

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләр раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрнең 2.1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба – Регламент, дәүләт хезмәте) билгели.

1.1.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Идарә) буйсынуындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең (алга таба – Ветеринария учреждениесе) Татарстан Республикасы территориясендә тотыла торган эт һәм аның хуҗасы турында белешмәләрне Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Мәгълүмат системасы) кертүне үз эченә ала.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: эт хуҗалары – милек хокукында яисә башка закон нигезендә этле булган физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гамәл кылучы затлар эш итә ала.

Әлеге Регламент нигезләмәләре түбәндәгеләргә кагылмый:

а) хезмәт хайваннарын тотуга һәм алардан файдалануга;

б) күрү сәләте буенча инвалидларны озата йөрүче этләрне йөртүгә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

**2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү (алга таба – этләрне теркәү).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

2.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Ветеринария идарәсе).

2.2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры Ветеринария учреждениесе күрсәтә.

Күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) этне теркәү (хуҗасы һәм аның эте турында белешмәләрне Мәгълүмат системасына кертү) һәм мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән форма буенча хәбәр итү.

2) этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яисә эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча хәбәр җибәрү;

3) әлеге Регламентка 4 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.3. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә сайланган ысул нигезендә җибәрелә:

почта аша кәгазь чыганакта;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы).

2.3.5. Этне теркәү турында хәбәр, Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты:

2.4.1. Дәүләт хезмәте гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән бирелгән очракта, Ветеринария учреждениесе тарафыннан гариза һәм шушы Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып өч эш көненнән дә артмаган вакытта күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм (шушы Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән) документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинет яки Республика порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Ветеринария учреждениесе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелә, алар Бердәм порталда шәхси кабинетта яисә Республика порталында шәхси кабинетта чагылдырыла.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Бердәм порталда, Республика порталында һәм Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://guv.tatarstan.ru/) урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Ветеринария учреждениесенең, Ветеринария учреждениесенең дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Этне теркәү өчен мөрәҗәгать итүче Ветеринария учреждениесенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза:

- турыдан-туры Ветеринария учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдәге документ рәвешендә (шушы Регламентка 1 нче кушымта);

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә шушы Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсе (турыдан-туры Ветеринария учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә бирелә).

Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә;

3) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык, тарату өчен шәхси белешмәләр субъекты рөхсәт иткән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

4) эткә милек хокукы яисә башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта);

5) этнең фотосы (мөрәҗәгать итүченең теләге буенча);

6) эт тәненә кертелгән электрон маркировкалау чарасы турында мәгълүматны үз эченә алган хайван паспортының уникаль цифрлы яисә хәрефле-цифрлы идентификация номеры булган күчермәсе (алга таба – микрочип).

2.6.2. Этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләр үзгәргән яки Мәгълүмат системасында булган этkә милек хокукы күчкән очракта, эт хуҗасы (этkә милек хокукы күчкәндә – яңа хуҗа) Ветеринария учреждениесенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза:

- турыдан-туры Ветеринария учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдәге документ рәвешендә (шушы Регламентка 1 нче кушымта);

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә шушы Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

2) мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсе (турыдан-туры Ветеринария учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә бирелә).

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документтагы белешмәләр БИАС системасында исәпкә алу язуын раслаган вакытта тикшерелә.

3) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык, тарату өчен шәхси белешмәләр субъекты рөхсәт иткән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

4) эткә милек хокукы яисә башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта);

5) этнең фотосы (мөрәҗәгать итүченең теләге буенча);

6) эт тәненә кертелгән микрочип турында мәгълүмат булган хайван паспорты күчермәсе.

2.6.3. Гариза һәм беркетелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Ветеринария учреждениесенә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) кәгазь чыганакларда шәхсән;

2) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә электрон рәвештә.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза белән имза сала.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында мәгълүмат бирелми.

2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш

тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) шушы Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларында каралган документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

2) гаризада һәм аңа теркәп бирелә торган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар, өстәп язулар һәм төзәтмәләр булу;

3) гариза рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес тутырмау;

4) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булу.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә мөрәҗәгать итүче ышанычнамә нигезендә эш итәргә вәкаләт бирмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

2) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр булган документлар тапшыру.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында, Идарәнең рәсми сайтында (http://guv.tatar.ru) бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.9.1. Дәүләт хезмәте Ветеринария учреждениесе тарафыннан түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү вакыты.

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән урыннарга урнаштырыла, көтү залларында (урында) мәгълүмат стендлары урнаштырыла, аларда Идарә һәм Ветеринария учреждениесенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаның аларны тутыру үрнәкләре белән формалары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Ветеринария учреждениесе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт

хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Ветеринария учреждениесе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Ветеринария учреждениесе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Идарәнең рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Ветеринария учреждениесе белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга карата прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Ветеринария учреждениесе белгечләре белән үзара эшчәнлек саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Бердәм портал һәм Республика порталы аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Ветеринария

учреждениесе белгече белән бер тапкыр хезмәттәшлек итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Ветеринария учреждениесе, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда һәм Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.4. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган

мәгълүматларга кагылышлы өлешендә, Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган мәгълүматлардан файдаланып, гаризаның электрон формасы кырларын тутыру;

5) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

6) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Ветеринария учреждениесенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Ветеринария учреждениесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Ветеринария учреждениесе вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында

техник мөмкинлек булганда, авторизация үтү шарты белән Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта мәгълүмат алына. Мөрәҗәгать итүче электрон гариза статусын, шулай ук Бердәм порталда шәхси кабинетта яки Республика порталында шәхси кабинетта үз инициативасы белән теләсә кайсы вакытта башкарылачак гамәлләр турында мәгълүматны карый ала.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вәкаләтле вазыйфаи зат булып Ветеринария учреждениесенең ветеринария учреждениесе боерыгы белән билгеләнә торган белгече тора.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша Ветеринария учреждениесенә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Ветеринария учреждениесе белгече шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә Бердәм портал яки Республика порталы ярдәмендә электрон рәвештә Ветеринария учреждениесенә гариза һәм шушы Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларында каралган документларны тапшыра.

Гариза Ветеринария учреждениесенә шәхсән бирелгән очракта, Ветеринария учреждениесе белгече тапшырылган документларның комплектлылыгын шушы Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктлары таләпләренә туры килүен тикшерә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән

әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Ветеринария учреждениесе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымта) язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Ветеринария учреждениесе белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта гаризаны терки.

Әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында билгеләнә торган процедуралар Ветеринария учреждениесенә гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Ветеринария учреждениесе белгече Бердәм порталга яисә Республика порталына гариза биргән вакыттан бер эш көненнән дә соңга калмыйча, ә ул эш көне булмаган яисә бәйрәм көнендә кергән очракта, аннан соңгы беренче эш көнендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне тәэмин итә.

Гаризаның керүе һәм теркәлүе турында электрон хәбәр Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта гаризаны карау статусында автомат рәвештә чагыла.

3.3.2.2. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә;

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Ветеринария учреждениесенә җибәрелгән электрон эш. Электрон гариза Ветеринария учреждениесе белгече өчен файдалана алырлык була.

3.3.3. Бердәм портал яисә Республика порталы аша Ветеринария учреждениесенә җибәрелгән гаризаны һәм документлар пакетын (электрон эшне) карау.

3.3.3.1. Административ процедураны башкара башлау өчен дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларында каралган документларның килүе нигез булып тора.

Ветеринария учреждениесе белгече Бердәм порталдан, Республика порталыннан көнгә кимендә 2 тапкыр кергән электрон гаризалар булу-булмавын тикшерә, кергән гаризаларны һәм документларның (документларның) кушымтадагы рәвешләрен карый.

3.3.3.2. Ветеринария учреждениесенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгече, документлар карауга алынганнан соң:

Гаризага эш номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелә, ул Бердәм порталда яки Республика порталында шәхси кабинетта чагыла.

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

техник мөмкинлек булган очракта, Бердәм порталга, Республика порталына керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаганда, электрон рәвештә кергән гарызнамәне ул алынган көнне яисә шушы эш көненең 16 сәгатеннән соң яисә ял (бәйрәм) көнендә алган очракта, икенче эш көнендә белешмәләр, документлар, материаллар бирү реестрында теркәүне тәэмин итә.

Әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әлеге Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Ветеринария учреждениесенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм дәүләт хезмәте

күрсәтү турында гариза кергән көнне мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталдагы шәхси кабинетка яисә Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза алынган көннән соң бер эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.3.3. Әлеге Регламентның 3.3.3.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3.3.4. Әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.4.1. Ветеринария учреждениесе белгеченә гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларында каралган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның килүе административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып тора.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләгәндә Ветеринария учреждениесе белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар җыелмасын карый;

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре ачыкланса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, бу Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны карау йомгаклары буенча этне теркәү турында хәбәр итү проектын (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) әзерли;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, шушы Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны карау йомгаклары буенча Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр проектын әзерли (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта);

этне теркәү турында әзерләнгән хәбәр проектын яисә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр проектын билгеләнгән тәртиптә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар гариза һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар кергән вакыттан алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Ветеринария учреждениесе җитәкчесенә килештерүгә юнәлдерелгән этне теркәү турында хәбәр проекты, Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр проекты яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проектына, этне теркәү турында хәбәр проектына яисә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр проектына (алга таба – документлар проектлары) Ветеринария учреждениесе җитәкчесе кул куя.

Кисәтүләре булган әзерләнгән документлар проектлары Ветеринария учреждениесе белгеченә эшләп бетерүгә кайтарыла. Кисәтүләр бетерелгәннән соң, документлар проектлары имзалау өчен кабат тапшырыла.

Ветеринария учреждениесе җитәкчесе тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган карар, этне теркәү турында хәбәр яисә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр Ветеринария учреждениесе белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтелгән документлар проектлары Ветеринария учреждениесе җитәкчесенә килештерүгә кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Ветеринария учреждениесе җитәкчесе тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган карар, этне теркәү турында яки Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында Ветеринария учреждениесе белгеченә җибәрелгән хәбәр.

3.4.4. Ветеринария учреждениесе җитәкчесе түбәндәгеләргә имза салган очракта, Ветеринария учреждениесе белгече:

этне теркәү турында хәбәр - этне теркәүне Мәгълүмат системасына эт һәм аның хуҗасы турында белешмәләр кертү юлы белән гамәлгә ашыра;

мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр - этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яисә эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертүне гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Мәгълүмат системасына эт һәм аның хуҗасы турында белешмәләр кертү юлы белән этне теркәү яки этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яки эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап Ветеринария учреждениесенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, Ветеринария учреждениесе белгече мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында хәбәрне, Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәрне яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта, электрон почта аша) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.4 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында бирелгән (җибәрелгән) хәбәр яисә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап бердәм портал яисә республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталдагы шәхси кабинетка яисә Республика порталындагы шәхси кабинетка этне теркәү турында хәбәрнең яки Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнең яисә Ветеринария учреждениесенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карарның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.4 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны) раслый торган документны Бердәм порталдан яки Республика порталыннан файдаланып җибәрү (бирү).

3.6. Техник хаталарны төзәтү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хаталар, грамматик хаталар) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 7 нче кушымта);

техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче Ветеринария учреждениесенә шәхсән үзе яисә Бердәм портал яисә Республика порталы аша бирә.

3.6.3. Ветеринария учреждениесе белгече кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны кабул итә һәм терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар тапшырылган (кергән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.6.4. Ветеринария учреждениесе белгече документларны карый һәм процедураларны әлеге Регламентның 3.3.1-3.5.2 пунктларында каралган тәртиптә башкара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент һәм дәүләт хезмәте үтәлешенә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына карата, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүгә агымдагы контрольлек Идарә җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү формасында башкарыла. Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр эш планнары нигезендә башкарыла. Планнан тыш тикшерүләр мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча уздырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә, Ветеринария учреждениесе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче Ветеринария учреждениесенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Ветеринария учреждениесе башлыгына шикаять белдерергә хокуклы.

Ветеринария учреждениесе башлыгы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Идарә башлыгына бирелә.

Идарә җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Идарәнең рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин (http://guv.tatar.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru/), Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/) аша, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең шикаятендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Шикаять кергән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында

мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Рәвеше

Җитәкче ______________________________
(район яисә шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе исеме)
______________________________

кемнән ______________________________
(Эт хуҗасының* Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))
______________________________
Шәхесне таныклаучы документ*:___________
сериясе _____________ номеры _____________,
бирелгән _____
______________________________
(кем тарафыннан, дата)
ИНН яки СНИЛС номеры*:
______________________
Яшәү урыны буенча теркәлү*: ______________
______________________________
Эт хуҗасының элемтә номеры:
______________________________
Электрон почта адресы:_______________________

Гариза

Мөрәҗәгать итүегезнең максатын сайлагыз* (V тамгасын куегыз):

- ☐ Этне теркәүне (эт һәм аның хуҗасы турында мәгълүматны Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертүне) гамәлгә ашыруны сорыйм.
- ☐ Этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яки эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына керту өчен мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Хайванның биологик төре | |
| Токымы (билгеле булса) | |
| Этнең туган көне | |
| Этнең төсе (буявы) | |
| Этнең җенесе | |
| Маркировкалау турында белешмәләр | |

| | |
|---|---|
| (маркировкалау датасы, маркировкалау чарасының исеме, маркировкалау чарасының номеры, маркировкалау чарасының тасвирламасы, маркировкалау чарасын беркетү, яисә кертү, яисә салу урыны, маркировкалауны гамәлгә ашырган зат (оешма) турында белешмәләр) | |
| Этне тотуның максаты | |
| Этне тоту тибы | |
| Этне тоту урыны | |
| Эт хуҗасы турында мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм физик затның шәхси счетының иминият номеры) | |
| Ата-аналарының уникаль номеры (әгәр этнең ата-анасы Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алынган һәм билгеле булса) | |
| Дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү турында (әгәр билгеле булса), шул исәптән дезинфекция, дегельминтизация, дезакаризация, профилактик вакцинация турында, дару препаратларын куллану турында белешмәләр | |
| Россия Федерациясенә кертү турында мәгълүматлар (кертү датасы һәм экспортлаучы ил, Россия Федерациясенә керткәндә хайванны озата барган ветеринария документының датасы һәм номеры) - читтән кертелгән этләр өчен | |
| Нәсел кыйммәте (нәсел кыйммәте юк, нәселле, билгеләнмәгән) | |

Мин белдерүдә күрсәтелгән барлык мәгълүматның дөрес булуын раслыйм.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен әлеге гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча кәгазьдә/электрон документ формасы буенча әлеге гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына җибәрүегезне сорыйм (кирәклесен ассызыкларга)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

«*» дип билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри була

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Житәкче ________________________________
(район яисә шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе исеме)
_______________________________________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ____________________________________________, таныклаучы документ
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
шәхесе: _____________________________________, бирелгән _____________________
___________________________________________________________________________________,
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
теркәлгән адресы: __________________________________________,
«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә «_________________________________
________________________________________________________________________________»
(учреждениенең тулы исеме)
дәүләт бюджет учреждениесенә, урнашкан адресы:
___________________________________________________,
(почта адресы күрсәтелә)
этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында, автоматлаштыру чараларын кулланып яисә мондый чараларны кулланмыйча, минем киләсе шәхси мәгълүматларым белән башкарыла торган теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасын башкаруга, шул исәптән белешмәләрне җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, файдалану), шәхессезләндерү, блоклау, бетерү, юкка чыгару) гамәлләрен башкаруга ризалык бирәм:

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта);
туу елы, ае, датасы һәм урыны;
гражданлык турында таныклык (кирәк булганда);
шәхесне таныклаучы документның реквизитлары;
салым түләүченең идентификацияләү номеры;
мәҗбүри пенсия иминияте таныклыгы номеры;
яшәү урыны һәм (яисә) тору урыны буенча факттагы яшәү һәм теркәлү урыны адресы;
телефон номеры, электрон почта адресы яисә почта адресы;
этне мәҗбүри теркәү өчен кирәк булган башка шәхси мәгълүматлар.

Мин танышып чыктым:

1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чыкканчыга кадәр гамәлдә була;

2) персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

3) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта,

_______________________________________________

(учреждениенең тулы исеме)

дәүләт бюджет учреждениесе «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2-11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булган очракта, шәхси мәгълүматларны эшкәртү дәвам иттерергә хокуклы;

4) өченче затларга карата бирелә торган шәхси белешмәләр бары тик ___________________________________________________________ дәүләт бюджет

(учреждениенең тулы исеме)

учреждениесенә йөкләнгәннәрне гамәлгә ашыру максатларында гына эшкәртеләчәк.

«__» _______ 20__ ел. ________________/___________________________________

(имза) (тулы имза)

Җитәкче ______________________________

(район яисә шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе исеме)

___________________________________________

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ________________________________________, таныклаучы документ

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

шәхесе: __________________________________, бирелгән

_____________________

______________________________________________________________________________,

(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

теркәлгән адресы: __________________________________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә

«_____________________________________________________________________

_________________________________________» дәүләт бюджет учреждениесенә

(учреждениенең тулы исеме)

урнашкан адресы: _______________________________________________

(почта адресы күрсәтелә)

Татарстан Республикасы территориясендә этләрне мәҗбүри теркәүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү максатында үзләренең шәхси белешмәләрен таратуга

(тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

фамилия, исем, ата исеме (булган очракта);

туу елы, ае, датасы һәм урыны;

гражданлык турында таныклык (кирәк булганда);

шәхесне таныклаучы документның реквизитлары;

салым түләүченең идентификацияләү номеры;

мәҗбүри пенсия иминияте таныклыгы номеры;

яшәү урыны һәм (яисә) тору урыны буенча факттагы яшәү һәм теркәлү урыны адресы;

телефон номеры, электрон почта адресы яисә почта адресы;

этне мәҗбүри теркәү өчен кирәк булган башка шәхси мәгълүматлар.

Мин танышып чыктым:

1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чыкканчыга кадәр гамәлдә була;

2) персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

3) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта ________________________________________________
(учреждениенең тулы исеме)
дәүләт бюджет учреждениесе «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2-11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булган очракта, шәхси мәгълүматларны эшкәртү дәвам иттерергә хокуклы;

4) өченче затларга карата бирелә торган шәхси белешмәләр бары тик ____________________________________________________ дәүләт бюджет
(учреждениенең тулы исеме)
учреждениесенә йөкләнгәннәрне гамәлгә ашыру максатларында гына эшкәртеләчәк.

«__» _______ 20__ ел. _________________/______________________________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Рәвеше

______________________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

Кемгә: ______________________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе,
исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)

________________ 20___ № __________

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________________________________________________________.

__________ ел, № __ , дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

1. ____________________;
2. ____________________;

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

______________/______________________________

(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

_____________________________________________

(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Рәвеше

______________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

Кемгә: ______________________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_______________ 20___ № __________

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
____________ № _____________ аңа кушымта итеп бирелгән документлар, түбәндәге нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. ____________________;
2. ____________________.

Күрсәтелгән хокук бозулар бетерелгәннән соң, сез кабат вәкаләтле органга дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

_______________/___________________________

(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

_____________________________________________

(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Рәвеше

____________________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Этне теркәү турында белдерү

__________________ «_____» _______ 20___ ел.

(торак пункт)

Әлеге ___________________________________________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

Сезнең токымлы эт турында мәгълүмат: ______________________________, кушаматы: _____________________________ микрочип № _________________________ Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертелде.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

______________/____________________________

(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

__________________________________________

(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Рәвеше

______________________________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр

____________________ «_____» ________ 20___ ел.
(торак пункт)

Әлеге ____________________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына токымлы эткә карата үзгәрешләр кертелүе турында хәбәр ителә: __________________________, кушаматы: _______________________ микрочип № ________________________, чөнки ________________________________________.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

_______________/___________________________
(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

____________________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Рәвеше

Җитәкче ________________________________
(район яисә шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе исеме)
____________________________________________

кемнән
____________________________________________
(Эт хуҗасының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))*

Шәхесне таныклаучы документ*:
____________________________________
сериясе ____________ номеры ____________,
бирелгән _____
____________________________________________
(кем тарафыннан, дата)
ИНН яки СНИЛС номеры*:
_____________________
Яшәү урыны буенча теркәлү*: _____________
____________________________________________
Эт хуҗасының номеры:
_____________________________
Электрон почта адресы:______________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына хуҗасы һәм аның эте турында белешмәләр кертү турында миңа бирелгән (җибәрелгән) хәбәрдә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне сорыйм

Төзәтергә кирәк булган мәгълүматлар: ___________________________________
____________________________________________________________________________.

Төзәтелгән мәгълүмат: __________________________________________
____________________________________________________________________________.

Гаризага кушымталар:

1.

2.

Мөрәҗәгать итүченең имзасы

Дата

«*» дип билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри була